**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2015, № 4; 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 38 (часть I); 2019, № 79 (часть I); 2020, № 26 (часть I) следующие изменения:

1) статью 7 изложить в следующей редакции:
«Статья 7. **Ордена, медаль ордена и медали Республики Татарстан**

Учреждаются следующие ордена, медаль ордена и медали Республики Татарстан:
орден «За заслуги перед Республикой Татарстан»;
орден «Дуслык»;
медаль ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан»;
медаль «За доблестный труд»;
медаль «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан»;
медаль «Родительская доблесть»;
медаль «Ана даны – Материнская слава»;
медаль «100 лет образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики»;
медаль «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны нефти Татарстана».»;

2) дополнить статьей $10^1$ следующего содержания:
«Статья $10^1$. **Положение о медали «Родительская доблесть»**

1. Медаль «Родительская доблесть» является высшей степенью признания института семьи и воспитания детей.

2. Медалью «Родительская доблесть» награждаются родители (усыновители) – граждане Российской Федерации, состоящие в зарегистрированном браке, либо родитель (усыновитель) – гражданин Российской Федерации, в случае смерти одного из родителей (усыновителей) или объявления его умершим, которые воспитывают или воспитали семерых и более детей в соответствии с требованиями семейного законодательства, при наличии не менее одного несовершеннолетнего ребенка.

Награждение медалью «Родительская доблесть» производится по достижении седьмым ребенком возраста семи лет и при наличии в живых остальных детей, за исключением случаев, предусмотренных настоящей статьей.

3. К награде представляются родители (усыновители), проживающие на территории Республики Татарстан не менее 10 лет, образовавшие социально ответственную семью, ведущие здоровый образ жизни, обеспечивающие надлежащий уровень заботы о здоровье, образовании, физическом, духовном и нравственном развитии детей, полное и гармоничное развитие их личности, подающие пример в укреплении института семьи и воспитании детей.

4. При представлении к награждению медалью «Родительская доблесть» учитываются также дети, погибшие или пропавшие без вести при защите Отечества или его интересов, при исполнении воинского, служебного или гражданского долга, умершие вследствие ранения, контузии, увечья или заболевания, полученных при указанных обстоятельствах, либо вследствие трудового увечья или профессионального заболевания, либо вследствие катастроф или стихийных бедствий.

5. Награждение медалью «Родительская доблесть» усыновителей производится при условии достойного воспитания и содержания усыновленных (удочеренных) детей не менее пяти лет.

6. При наличии у гражданина ордена «Родительская слава» награждение медалью «Родительская доблесть» не производится.

7. Граждане, удостоенные медали «Родительская доблесть», носят ее на левой стороне груди, а при наличии у награжденных других орденов и медалей располагают после медали «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан».»;

3) в статье 11:

а) дополнить частью $5^1$ следующего содержания:

«$5^1$. При наличии у гражданина медали «Родительская доблесть» награждение медалью «Ана даны – Материнская слава» не производится.»;

б) часть 6 изложить в следующей редакции:

«6. Граждане, удостоенные медали «Ана даны – Материнская слава», носят ее на левой стороне груди, а при наличии у награжденных других орденов и медалей располагают после медали «Родительская доблесть».»;

4) часть 2 статьи 37 изложить в следующей редакции:

«2. Гражданам, награжденным медалью «Родительская доблесть», медалью «Ана даны – Материнская слава», наряду с мерами социальной поддержки, предусмотренными частью 1 настоящей статьи, выплачивается единовременное денежное вознаграждение в порядке и размерах, определяемых Президентом Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
27 декабря 2021 года
№ 106-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш), 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасы орденнары, орден медале һәм медальләре**

Татарстан Республикасының түбәндәге орденнары, орден медале һәм медальләре гамәлгә куела:

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены;

«Дуслык» ордены;

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале;

«Фидакарь хезмәт өчен» медале;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале;

«Ата-ана фидакарьлеге» медале;

«Ана даны – Материнская слава» медале;

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале;

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге $10^1$ статья өстәргә:

«10$^{1}$ статья. **«Ата-ана фидакарьлеге» медале турында нигезләмә**

1. «Ата-ана фидакарьлеге» медале гаилә һәм балалар тәрбияләү институтын тануның иң югары дәрәҗәсе булып тора.

2. «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән җиде һәм аннан да күбрәк баланы гаилә законнары таләпләре нигезендә тәрбияләүче яисә тәрбияләгән, кимендә бер балигъ булмаган балалары булганда, теркәлгән никахта торучы ата-аналар (уллыкка алучылар) – Россия Федерациясе гражданнары йә, ата яки ананың (уллыкка алучының) берәрсе үлгән яисә үлгән дип игълан ителгән очракта, ата яки ана (уллыкка алучы) – Россия Федерациясе гражданы бүләкләнә.

«Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләү, әлеге статьяда каралган очраклардан тыш, җиденче балага җиде яшь тулгач һәм калган балалар исән булган очракта башкарыла.

3. Бүләккә Татарстан Республикасы территориясендә кимендә 10 ел яшәүче, социаль җаваплы гаилә коручы, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, балаларның сәламәтлеге, белеме, физик, рухи һәм әхлакый үсеше турында кайгыртуның тиешле дәрәҗәсен һәм аларның шәхес буларак тулысынча һәм һәрьяклап үсешен тәэмин итүче, гаилә институтын ныгытуда һәм балаларны тәрбияләүдә үрнәк күрсәтүче ата-аналар (уллыкка алучылар) тәкъдим ителә.

4. «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә шулай ук Ватанны яисә аның мәнфәгатьләрен яклаганда, хәрби бурычларны, хезмәттәге яки граждан бурычын үтәгәндә һәлак булган яисә хәбәрсез югалган, шулай ук күрсәтелгән шартларда яралану, контузия алу, гариплэнү яисә авыру сәбәпле, йә хезмәттә гариплэнү яисә һөнәри авыру аркасында, йә һәлакәтләр яисә табигый бәла-казалар аркасында вафат булган балалар да исәпкә алына.

5. Уллыкка бала алучыларны «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләү уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны кимендә биш ел дәвамында лаеклы тәрбияләү һәм карап тоту шарты белән башкарыла.

6. Гражданның «Ата-ана даны» ордены булган очракта, «Ата-ана фидакарьлеге» медале бирелми.

7. «Ата-ана фидакарьлеге» медаленә лаек булган гражданнар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медаленнән соң урнаштыралар.»;

3) 11 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлектәге 5$^{1}$ өлеш өстәргә:

«5$^{1}$. Гражданның «Ата-ана фидакарьлеге» медале булган очракта, «Ана даны – Материнская слава» медале бирелми.»;

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Ана даны – Материнская слава» медаленә лаек булган гражданнар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, «Ата-ана фидакарьлеге» медаленнән соң урнаштыралар.»;

4) 37 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Ата-ана фидакарьлеге» медале, «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән гражданнарга, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган социаль ярдәм чаралары белән беррәттән, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмдә бер мәртәбә акчалата бүләкләү бирелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 106-ТРЗ